Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Юлсубино авыл җирлеге Советы

**КАРАР №3**

Юлсубино авылы 2020 елның 22 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Юлсубино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Юлсубино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 маддәләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Юлсубино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 19,86,87,88 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 апрелендәге 10 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Юлсубино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советының 01.12.2016 ел 20, 25.07.2017 ел 7, 27.04.2018 ел 6, 07.04.2020 ел 5 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) кушымтага ярашлы рәвештә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда юстиция органнарына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алынганнан соң http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда игълан итәргә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56а йорт; Ямаш авылы, 3в йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсенең 8 олеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Уставының 88 маддәсенең 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Юлсубино авыл җирлеге Х.Х.Гатиятов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Юлсубино авыл
җирлеге Советының
2020 елның 22 октябрендәге
3 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы**
**"Юлсубино авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына**
**үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Юлсубино авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 6 маддәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 16 пунктча өстәргә:

"16) полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәрнең күрсәтелгән вазыйфаны биләве чорында торак урыны бирү.";

2) 23 маддәнең 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

"3. инициатив проектны тормышка ашыру тәкъдим ителә торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегендә яки аның бер өлешендәге уналты яшькә җиткән яшәүчеләрне (-ң) – бу инициатив проектны хуплау турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.";

3) 23 маддәнең 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Гражданнардан сораштыруны билгеләү турында карар җирлек Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен муниципаль берәмлекнең "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты файдаланылырга мөмкин. Җирлек Советының гражданнардан сораштыруны билгеләү турындагы карарында түбәндәгеләр тәгаенләнә:

1) сораштыруны уздыру датасы һәм сроклары;

2) сораштыру уздырганда тәкъдим ителә торган сорауның (сорауларның) формулировкасы (тәгъбирләнеше);

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазенең рәвеше;

5) сораштыруда катнашучы муниципаль берәмлек халкының минималь саны;

6) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып гражданнардан сораштыру үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү (таныклау) тәртибе;.

5) 57 маддәнең 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Муниципаль вазыйфаны даими булмаган нигездә биләүче затка әлеге маддәнең 2 өлешендәге 1 - 4 һәм 10 пунктларында күздә тотылган гарантияләр бирелә, аның тарафыннан муниципаль вазифаны биләү белән бәйле чыгымнарны каплау гарантияләнә, шул исәптән муниципаль вазифа биләүгә бәйле рәвештә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә хезмәт командировкалары белән бәйле чыгымнарны, шулай ук дәвамлылыгы Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль берәмлек уставында билгеләнә торган чорга эш (вазыйфа) урынын саклау гарантияләнә һәм ул тулаем алганда аена җыенысы ике эш көненнән кимрәк һәм алты эш көненнән күбрәк була алмый.”.

6) 2021 елның 1 гыйнварына чаклы 79 маддәнең 3 өлешенең, 84 маддәнең 5 өлешенең гамәлдә булуын туктатып торырга.